# 307 нче номерлы балалар бакчасы музыка җитәкчесенең Эш программасына аннотация.

2 яшьтән 7 яшькә кадәрге балаларны музыкаль тәрбияләү һәм үстерү буенча Музыка җитәкчесенең эш программасы, 307 нче номерлы балалар бакчасының норматив документы булып тора.

Музыка җитәкчесенең эш программасы (алга таба-Программа)

2 яшьтән 7 яшькә кадәрге балалар өчен) 2021-2022 уку елына түбәндәге таләбләрне үз эченә кертеп эшләнелде:

- 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы " Россия Федерациясендә белем бирү»;
- Федераль дәүләт мәгариф стандарты ,Министрлык боерыгы белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 17 октябрендәге 1155 номеры белән теркәлгән;
- Баш дәүләт санитария табибы карары нигезендә расланган Россия Федерациясенең 28.09.2020 ел, №28 «СП 2.4.3648-20 теркәлгән, санитар-эпидемиологик таләпләрне дә үз өченә ала.

Эш " Мәктәпкәчә белем бирүнең (“От рождения до школы”)төп программасы Н.Е. Веракса, Т. С. Комарова, М. А. редакциясе астында туган ( алтынчы басма, Мозаика-Синтез, 2019) программага нигезләнеп төзелде.

Программа продуктив эшчәнлекнең төп юнәлешләрен, шартларын һәм чараларын билгели, балалар бакчасы шартларында музыка сәнгате дөньясы белән таныштыра һәм гомуми культураны формалаштыруга, физик, интеллектуаль һәм шәхес сыйфатларын үстерүгә, балаларның сәламәтлеген саклап калуны һәм ныгытуны тәэмин итә торган уку эшчәнлеге алшартларын формалаштыруга юнәлдерелә.

Эш программасының бурычлары :

- Гомуми музыкаль үсеш.
- Музыкаль - уен эшчәнлеге нигезендә уен күнегүләре системасы аша музыканы актив кабул итүне формалаштыру.

Программада , балаларның яшьләренә туры китереп максат һәм бурычлар куелган. Музыкаль - эстетик үсеш процессын тормышка ашырганда музыка сәләте һәм мәктәпкәчә балачакта төрле музыка эшчәнлегенә сәләтләр комплексы буларак музыкальлекне күрсәтүнең яшь үзенчәлекләре исәпкә алынды. Әлеге программаның үзенчәлеге-региональ компонентны кертү.

Хәзерге педагогиканың иң мөһим проблемаларының берсе халык традицияләре,милли мәдәният һәм -патриотик тәрбия тора. Бүгенге көндә патриотик тәрбия бирү, шәхесне үстерү проблемасы, аның эстетик культурасын формалаштыру мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре алдында торган иң мөһим бурычларның берсе. Болар барысы да уен аша үрелеп барганда гына зур уңышка ирешергә мөмкин.

Программада балаларның , белем бирү өлкәләренең үзенчәлекләре һәм мөмкинлекләре нигезендә ,интеграцияләү принцибы салынган

Эчтәлекле өлеше, белем бирү эшенең түбәндәге юнәлешләре белән тәкъдим ителә:

1) музыканы кабул итү.
2) җырлау.
3) музыкаль-ритмик хәрәкәтләр.
4) балалар музыка коралларында уйнау.
5) балалар иҗатын үстерү (җыр, музыкаль-уен, бию).

Музыкаль үсеш алымнары:

1) Күргәзмә:.
2) Сөйләм үстерү: музыка турында сөйләшүләр.
3) Тыңлау: җырлау. музыка тыңлау.
4) уен: музыкаль уеннар.
5) практик: җырларны, биюләрне өйрәнү, көйләр уйнау.

Программаларда балаларның Музыка эшчәнлеген яшь мөмкинлекләре нигезендә оештыру формалары билгеләнгән, барлык яшь төркемнәренә перспектив планлаштыру, диагностик критерийлар, методик һәм матди-техник тәэмин итү бар. Эш программаларын гамәлгә ашыру педагогларның балалар белән булган фронталь һәм индивидуаль -белем бирү эшчәнлеге аша башкарыла.